СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 4-30 «17» декабрь 2018 ел

Мамадыш муниципаль районында физик культураны һәм спортны, яшьләр сәясәтен үстерү турында

Муниципаль район башкарма комитетының «Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» МУ җитәкчесе А.П. Смирновның Мамадыш муниципаль районында физик культура һәм спортны, яшьләр сәясәтен үстерү турында докладын тыңлаганнан соң, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль район Советы **карар кабул итте:**

1. Муниципаль район башкарма комитетының «Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» МУ җитәкчесе А.П. Смирновның Мамадыш муниципаль районында физик культура һәм спортны, яшьләр сәясәтен үстерү турында докладын игътибарга алырга.

2. Мамадыш муниципаль районының башкарма комитетына «Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» МУ белән берлектә тәкъдим итәргә:

- физик культура, халыкның төрле категорияләре спорт белән даими шөгыльләнү өчен яшәү, уку, хезмәт эшчәнлеге урыннарында һәркем файдалана алырлык шартлар тудыру, шул исәптән физик мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр өчен дә;
- яшьләр арасында сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауны һәм физкультура-савыктыру эшен активлаштырырга;
- физкультура-спорт хезмәтләренең, шул исәптән түләүле хезмәтләрнең һәркем файдалана алырлык булуын, төрлелеген һәм сыйфатын арттыруны тәэмин итәргә;
- халыкка спорт юнәлешендәге муниципаль учреждениеләр күрсәтә торган хезмәтләрнең сыйфатын яхшырту өчен физик культура һәм спорт өлкәсендә бюджет акчаларыннан файдалануның нәтиҗәлелеген арттырырга;
- муниципаль район яшьләренең тормыш эшчәнлеген, мәгарифен һәм тәрбиясен, физик, рухи һәм әхлакый үсешен тәэмин итү өчен шартлар тудыру;
- Мамадыш муниципаль районында һәм Татарстан Республикасында яшьләрнең дәүләт яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның барышы турында яшь гражданнарга, яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләренә мәгълүмат бирү өчен массакүләм мәгълүмат чараларыннан актив файдалану.

3. Авыл җирлекләре башлыкларына, милек формасына бәйсез рәвештә оешма-предприятиеләргә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә балаларны һәм яшьләрне, шул исәптән физик мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрне җәлеп итүгә юнәлдерелгән чараларны камилләштерү буенча планлы эш алып барырга тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында, " Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында http://mamadysh.tatarstan.ru. веб-адресы буенча игълан итәргә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль район Советының социаль мәсьәләләр, сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, яшьләр сәясәте һәм спорт буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район Башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе А.П.Иванов